Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№38 (51)
27 декабрь 2012 ел

*Хөрмәтле мөгаллимнәр, студентлар, хезмәткәрләр!*

*Сезне Казан федераль университеты җитәкчелеге һәм шәхсән үз исемемнән ихлас күңелдән якынлашып килүче Яңа 2013 ел белән тәбрик итәм.*

*Табигый халәт: елны озатканда, һәркайсыбыз да башкарылган эшләргә, кылынган гамәлләргә йомгак ясыйбыз, нәтиҗәләр чыгарабыз. Узып барган ел үзенең куанычлы мизгелләре, борчу-мәшәкатьләре, табышлары һәм югалтулары белән күңелләргә кереп калыр. Безнең югары уку йорты өчен дә 2012 ел, тулаем алганда, яңарыш, алгарыш елы булды. Алга таба да бурычыбыз – ил, дөнья күләмендә танылган югары уку йортының дәрәҗәсен тагын да үстерү, уку-укытуда иң алдынгы инновацион алымнарны кертү, матди базаны ныгыту, студентлар өчен югары белем алуда бар мөмкинлекләрне дә куллану. Без бердәм булганда, боларның барысына да ирешербез, чөнки бердәмлек һәм бер максатка омтылыш һәр уңышның нигезен тәшкил итә. Яңа 2013 елның иң мөһим вакыйгасы: бөтендөнья студент-яшьләренең җәйге Универсиадасы. Безнең югары уку йорты да бу чарада иң актив катнашучыларның берсе һәм республика данын яклаучы булачагына һич шигем юк. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Казан федераль университетында бара торган уңай үзгәрешләрне тормыш үзе таләп итә. Данлыклы уку йортыбызның үсешенә һәм тотрыклылыгын саклауга зур өлеш кертүегез өчен барыгызга да зур рәхмәтемне белдерәм.*

*Киләсе ел исә һәркайсыбызга да бары тик уңышлар, шатлыклы мизгелләр, яңадан-яңа ачышлар, Ватаныбыз – Россия, туган республикабыз – Татарстанга иминлек алып килсен. Хыял-теләкләрегез, максатларыгыз тормышка ашсын. Сезгә ныклы сәламәтлек, күңел көрлеге, иман байлыгы, эшчәнлегегездә яңа үрләргә ирешүне, укуыгызда уңышлар, бәхет-сәгадәт телим. Яңа елларыбыз якты булсын, һәр туар таң өмет-ышаныч бүләк итсен!*

**Ихтирам белән, ректор Илшат Гафуров.**

# Яңа 2013 ел белән!



Руслан Гыйниятов, фотосы

# «Ачыш хәрәкәттә генә ясала!»

**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрче

2012 ЕЛГА НӘТИҖӘЛӘР ЯСАГАНДА, УКУ ЙОРТЫБЫЗ РЕКТОРЫ ИЛШАТ ГАФУРОВ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАССАКҮЛӘМ МАТБУГАТ ЧАРАЛАРЫ ВӘКИЛЛӘРЕ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ.

Беркемгә дә сер түгел, соңгы арада матбугатта уку йортыбыз, аның җитәкчелеге, эшчәнлеге турында имеш-мимешләр артып китте. Ни өчен имеш-мимеш, чөнки кайбер мәгълүматларның чыганагын җитәкчелек үзе дә аңлап бетерми. Бу уңайдан КФУ ректоры Илшат Гафуров, узган елгы традицияне саклап, журналистларны кунакка җыйды. Башта алар уку йорты, структурасы, университет телевидениесе белән танышты, соңгы үзгәрешләрне үз күзләре белән күрде.

Түгәрәк чәй өстәле артында узган очрашуны ректор рәхмәт сүзләре белән башлап җибәрде. «Безгә карата булган игътибарыгыз өчен рәхмәт. Күп кенә кәефне төшерердәй язмалар да укырга туры килде. Бу, әлбәттә, федераль университет составына алты уку йорты кушылу белән аңлатыла. Әйтергә кирәк, үзгәрешләрне зур каршылыкларсыз җиңеп чыктык. Бүгенге көндә бездә 47 401 студент белем ала», – диде һәм чыгышын КФУның эшчәнлегенә бәйле презентация белән дәвам итте.

Очрашуга килгән журналистлар да үзләрен бик актив тотты. «Университет танылган шәхесләре белән дан тота. Горурланырлык галимнәребез бик күп, ләкин аларның дөнья күләмендә билгеле булганнары берничә генә. Әйтик, XIX гасырда – Н.И.Лобачевский, XX гасырда – Е.К.Завойский. Киләчәктә дә шундый зур галимнәр булыр микән?» – дигән сорауга җитәкче: «Әлбәттә, булачак. Бер генә зур галимне дә үсеш ясаган көнне үк танымаганнар. Н.И.Лобачевский да, Е.К.Завойский да исән вакытта тиешле бәяне алмаган. Мәсәлән, Завойский 1943 елда магнитлы резонансны ачуын белми дә кала. Аның яңалыгын дәвамчылары эшләп бетерә. Ватандашыбыз, Нобель премиясе лауреаты Ж.И.Алферов: «Вакыт дигән әйбер бар. Шуңа буйсынырга гына кирәк. Шул вакыт дәвамында тикшеренүләр тормышка ашырыла. Һәм без моңа тәэсир итә алабыз», – дигән иде. Ачыш хәрәкәттә булганда гына ясала. Аның өчен эзләнергә, тикшеренүләр үткәрергә кирәк. Менә без откан грантлар фундаменталь фәннәрне алга җибәрердәй лабораторияләр, фәнни кампуслар ачарга ярдәм итә. Башкарган хезмәтебез нәтиҗәсез калмас», – дип җавап кайтарды. «Ә галимнәр акча эшләп калырга гына теләмиләр микән?» – дигән сорауга кырт кисеп: «Юк, – диде, – Алар акча эшләргә омтылмый да. Ясаган ачышларыбыз урын тапсын өчен, без эшләргә тиеш. Ләкин аларның кайда һәм ничек кулланылачагы шулай ук вакыт эше. Әйтик, без берәр яңа әйбер уйлап табарга мөмкин, ләкин технологияләр аны тормышка ашыра алмый. Ничек кенә булмасын, без туктап калырга тиеш түгел».

Үзләре дә шул бүлекне тәмамлаган журналистларны журфак язмышы борчый. «Быел журналистика өлкәсендә дә зур үзгәрешләр булды. 2006 елда факультетка бер төркем студентларны халыкара журналистика бүлегенә кабул иттеләр. Ләкин алар да гадәти төркемнәр белән бер дәрәҗәдә укып йөрде. Бернинди чит илләргә чыгу да булмады. Менә институт дәрәҗәсенә җиткәч, нинди үзгәрешләр булыр икән?» Бу уңайдан да ректор үз фикерен җиткерде: «Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты безгә яңа укыту программасы тәкъдим итәчәк. Анда игътибар күбрәк электрон журналистикага бирелергә тиеш, чөнки киләчәктә интернет ресурсларның өстенлек алачагы көн кебек ачык. Коры журналистлар гына әзерләү дә дөрес түгел. Ул ниндидер өлкәдә белгеч булырга тиеш. Фән, спорт, автомобиль турында берни белмәгән, химия-физиканың нәрсә икәнен аңламаган кеше алар турында яза да алмый. Шундый мәзәк тә бар бит. Берәү баласын журналист итәргә хыяллана икән. Икенче берәү аңа: «Соң ул бит яза да белми», – дигәч, тегесе: «Ә аңа язарга кирәкми дә, ул тележурналист булачак», – дип җавап кайтарган. Кайвакыт журналистларга профессиональлек җитеп бетми. Бу – безнең проблема һәм аны без хәл итәргә тиеш. Журналистларны аерым бинага күчергәч тә, төрле сүзләр йөрде. Шуңа күрә бу үзгәрешләргә саклык белән карыйбыз. Без аларга эшләү, лабораторияләр ачу өчен аерым мөмкинлекләр тудырырга телибез», – диде. Сүз уңаеннан, мисал итеп Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтын китерде. Биредә хәзер яңа программа буенча чит телләр генә түгел, ә ул илләрнең тарихын, мәдәниятен, икътисадын, хокукын да өйрәтәләр. Яңа төбәкне өйрәнү кафедрасы ачылган. Аның җитәкчесе булып, ислам икътисады буенча яшь белгеч Ринат Бекин тора. «Исламны сезнеке-безнекенә бүлеп карый башладылар. Бу алай булырга тиеш түгел, гасырлар буена килгән традицияләрне саклау мөһим. Моның өчен конференцияләр, аралашулар гына җитми, ә фәнни эзләнүләр дә кирәк. Проблемаларның каян килеп чыкканын өйрәнергә тиешбез. Шуның өчен башка илләрдән галимнәрне чакырабыз. Уку йортыбызда VIII көнчыгышны өйрәнүчеләр җыенын үткәрдек һәм алдагы ике елга шәрыкны өйрәнү үзәге итеп билгеләндек. Димәк, без тагын игътибар үзәгендә», – диде ректор Илшат Гафуров.



*Рәсемдә сулдан уңга: Е.Чернобровкина (Бизнес-онлайн газетасы) и О.Корякин (Российская газета).* Алия Галимуллинина фотосы

***Дәвамы алдагы санда.***

## • Универ хәлләре

**23 ДЕКАБРЬ КӨННЕ ЧИРАТТАГЫ РЕКТОРАТ УТЫРЫШЫ УЗДЫ.** Илшат Гафуров җыелышта катнашучылар игътибарына Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институтының яңа директоры – **МӨХӘРРӘМОВ НАИЛ МИДХӘТ** улын тәкъдим итте. Аның хезмәт эшчәнлеге турында сөйләде.

Утырышта республика мәктәпләрендә КФУның махсус стендларын булдыру турында сүз барды. Аларны кайсы мәктәпләрдә урнаштыру кирәклеге, стендларда кире элемтә мөмкинлеген булдыру мәсьәләләре хәл ителде. Моннан тыш, мәктәпләрдә университетыбыз хәлләре белән таныштырган мониторлар булдыру планлаштырыла.

Ректор И.Гафуров КФУның һәр бүлек җитәкчесенә 2013 елга финанслар бүленеше турындагы планнар һәм 2014 елга фаразлар җиткерүләрен сорады.

КФУ аппараты җитәкчесе, административ эшчәнлек буенча проректор **АНДРЕЙ ХАШОВ** чаралар планын тәкъдим итте, соңгы боерыкларның үтәлеше турында сөйләде.

КФУның Яр Чаллы филиалы директоры Мәхмүт Ганиев филиалның вакытлыча оештыру структурасын тәкъдим итте. КФУның мәгълүматлаштыру һәм элемтә депертаменты җитәкчесе Дмитрий Бурмистров интернет кулланучыларны kpfu.ru доменында урнашкан яңа сервис турында сөйләде.

КФУ ның Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты профессоры **РЕНАТ ХӘЛИУЛЛА УЛЫ МӨСЛИМОВКА** «Скважина һәм пластларга термо- һәм гидродинамик тикшеренүләр үткәргәндә яңа ысуллар» исемле хезмәте өчен Губкин исемендәге премия бирелде.

• • • •

**20 ДЕКАБРЬ КӨННЕ** А.М.Бутлеров ис. Химия институты галимнәре- физик химия кафедрасы җитәкчесе **БОРИС СОЛОМОНОВ**, шул ук кафедраның фәнни хезмәткәре **ИГОРЬ СЕДОВ** вузга кадәрге, гомуми һәм педагогик белем бирү буенча ректор ярдәмчесе **ЛЮДМИЛА НУГУМАНОВА** җитәкчелегендә **IT-ЛИЦЕЙ УКУЧЫЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ**. Борис Соломонов укучыларны химия институтында эшләгән юнәлешләр, олимпиадалар һәм башка шундый кызыклы чаралар белән таныштырды.

• • • •

**25 ДЕКАБРЬ КӨННЕ** Казан ратушасында мэр стипендиясенә лаек булучы студент һәм аспирантларны **БҮЛӘКЛӘҮ ТАНТАНАСЫ БУЛДЫ**. Стипендиягә лаеклы дип табылган 38 иң тырыш, иң актив конкурсантның 13е Казан федераль университеты студентлары һәм аспирантлары.

• • • •

Шул ук көнне Педагогика һәм психология институтының актлар залында КФУда эшләүчеләрнең һәм укучыларның балалары өчен **ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ ОЕШТЫРЫЛДЫ**. Тантананы ректор Илшат Гафуров ачып җибәрде. Мондый төрдәге бәйрәмнәрне ул һәр елны үткәрергә тәкъдим итте. Бәләкәчләр белән Филология һәм сәнгать, Педагогика һәм психология институты студентлары күңел ачты.

• • • •

**22 ДЕКАБРЬ КӨННЕ** универсиада авылында тантаналы рәвештә **БЕРНИЧӘ ИНФРАСТРУКТРУРА ОБЪЕКТЫ АЧЫЛДЫ**. Берсе – зур сәүдә үзәге, ә икенчесе – матурлык салоны. Киләчәктә биредә студентлар өчен спорт мәйданчыклары да төзү күздә тотыла.

• • • •

Казан федераль университеты Интернет челтәрендә үткәрелгән **ТӨБӘКАРА ФӘН ОЛИМПИАДАЛАРЫНА ЙОМГАК ЯСАДЫ**. Октябрь аеннан декабрьгә кадәр дәвам иткән бу бәйгедә барлыгы 15 меңнән артык мәктәп укучысы катнашкан. Укучыларның күбесе математика буенча катнашырга теләк белдергән. Рус телен сайлаучылар алучылар аннан аз гына калышкан. Сайлап алучылар саны буенча өченче урында рус әдәбияты. Мондый төрдәге интернет-олимпиадалар оештыру КФУдагы өстенлекле юнәлешләрнең берсе.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

# Казан федераль университ

Хөрмәтле укучылар! Яңа елны каршы алыр алдыннан, һәркем узган елга нәтиҗә ясый. Без дә артыбызга борылып карадык та, Казан (Идел буе) федераль университетында ел дәвамындагы вакыйгаларга йомгак ясарга булдык. Университетыбызның еллык тормышына бергәләп күз салыйк әле.







## ГЫЙНВАР

**КФУга Польшаның Лодзин воеводалыгыннан делегация килде. Очрашу барышында, Россия-Польша фәнни үзәге оештыру турында килешенде.**

**КФУга Массачусет технология институтыннан (MIT) бер төркем студентлар һәм аспирантлары килде.** «Технологик эшмәкәрлекне үстерү: Россиядә һәм АКШта студентларның инновацион эшчәнлек тәҗрибәсе» дигән түгәрәк өстәлдә Америка студентлары, аспирантлары институттагы мөмкинлекләр белән таныштырды.

**Россия һәм Татарстанның вуз ректорлары РФ мәгариф һәм фән министры Андрей Фурсенко белән очрашты.** Анда «Студентларның мөстәкыйльлеге» турында сөйләшү булды. Бу көнне РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы белән «Студентлар баскетболы ассоциациясе» арасында килешүгә кул куелды.

**Университетка НАТОның Мәскәүдәге Мәгълүмати бюросы директоры Роберт Пшель килде.** Ул «Россия һәм НАТО арасындагы мөнәсәбәтләр» темасына лекция укыды.

**ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов КФУда ТРның аспирант-студентлары, югары, урта һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениесе укучылары – махсус дәүләт стипендиатлары белән очрашты.** КФУдан әлеге мәртәбәле бүләккә 17 студент һәм аспирант лаек булды.

**«Ак Барс» Банк квалификацияне арттыру сертификатларын тапшырды.** «Ачык университет» программасын үткән Икътисад һәм финанс интситуты, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтының 38 чыгарылыш студентына тапшырдылар. Алар «Ак Барс» Банк белән ике елга Хезмәт килешүе төзеде.



**Студентлар көне уңаеннан уздырылган тантаналы чарада Илшат Гафуров та катнашты.** Концерт ректорның котлау сүзләре белән башланып китте. Ул сәхнәгә байкер костюмыннан мотоциклда чыкты.

**Төрле дәүләт оешмаларында эшләүче белгечләр мөрәҗәгате буенча Филология һәм сәнгать институтында ТРның Министрлар Кабинеты ярдәме белән татар теле курслары оештырылды.** Курслар 3 ай (февраль-апрель айлары) дәвам итте.

## ФЕВРАЛЬ

**10 февраль көнне Россиянең юристлар ассоциациясе оештырган «Чиста сайлаулар өчен» күзәтүчеләр корпусы активистлары юридик факультет студентлары белән очрашты.** Ул 4 мартта узган РФ Президентын сайлауга багышланды.

**Актлар залында «2011 елның иң яхшы яшь галиме» республика конкурсының җиңүчеләрен өч номинация буенча бүләкләделәр.** «Табигый фәннәр өлкәсендә иң яхшы яшь галим» исеменә КФУның микробиология кафедрасының өлкән укытучысы Равил Фәхруллин ия булды.



**КФУ һәм А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты арасында** фракталь структуралар синтезы технологияләре һәм катлаулы техник системалар лабораториясе булдыру турындагы **килешүгә кул куелды**. Лаборатория вузара һәм фәнара бәйләнешлар даирәсен тагын да киңәйтә.

**КФУга Франциянең Страсбург университеты профессоры Александр Варнек килде.** Страсбург университеты безнең уку йорты белән 2003 елдан бирле хезмәттәшлек итә. Алга таба уртак лабораторияләр, магистр программалары ачу күздә тотыла.



**14 февраль көнне Илшат Гафуров РФ Хөкүмәте рәисе Владимир Путин белән узган очрашуда** Президентлыкка кандидатның ышанычлы кешесе буларак **катнашты**. Очрашуда бик күп мәсьәләләр күтәрелде. Ул социаль, Россия Президенты стипендияләренә кагылышлы мәсьәләләрне күтәрде.

**КФУ ректоры Илшат Гафуров катнашында Schlumberger («Шлюмберже») иң эре нефтесеврис компаниясе вәкилләре белән очрашу узды.** Компания вәкиле Андрей Аверин күп функцияле үзәкне тәкъдим итте.

**Туган тел көнендә** «Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар» исеме астында **III Республика фәнни-гамәли конфренциясебулды.** Бирегә Татарстаннан гына түгел, Башкортстан, Пермь кебек чит төбәкләрдән килүчеләр дә бар иде.

**Физика институтында Илдар Гыйльметдинов исемендәге стипендия тапшыру тантанасы булды.** Бу семестрда стипендиягә институт студентлары Фәнис Хәкимов һәм Гөлия Вәлиуллина лаек булды. Исегезгә төшерәбез, әлеге стипендия семестрга бер, яхшы билгеләргә генә укыган, җәмәгать эшләрендә актив катнашкан, спортта уңышлары булган студентларга тапшырыла. Илдар әфәнде заманында үзе дә физика факультетын тәмамлаган.

**КФУда РФ финанс министры, дөньяның алдынгы компанияләреннән белгечләр катнашында Планетарий төзү буенча җыелыш узды.** Бездә ике төрле – горизонталь яки вертикаль Планетарий төзелә ала. Ректор фикеренчә, аның төп максаты: белем бирү процессында кулланылу һәм керем китерү.

**26 февраль КФУда Ачык ишекләр көне узды.** Барлыгы РФның 12 субъектыннан 1200 ләп укучы катнашты. Аларга уку йорты эшчәнлеге, мәдәни чаралар, спорт тормышы турында мәгълүмат җиткерелде.

**«УНИКС» концертлар залында «Кризисның сәбәпләре. 2012 елда Казанны, Россияне һәм дөньяны нәрсә көтә?» дигән темага ачык лекцияләрүтте. «Казанда «креатив сыйныф»ның перспективалары» темасына Казан мэры Илсур Метшин чыгыш ясады.** Дөнья буйлап сибелгән каршылыклар дулкыны хакында International Academy of Science академигы, МДУ галиме Андрей Фурсов сөйләде. «Сары инкыйлаблар»ның технологияләре: Сербия, Украина һәм Мисырдан Россиягә кадәр» темасын исә күп еллар дөньякүләм демократиягә бәйле мәсьәләләрне өйрәнгән сәясәт фәннәре докторы, Мәскәү дәүләт халыкара багланышлар институты профессоры Елена Пономарева яктыртты.



**КФУ Татарстан башлыгын – Рөстәм Миңнехановны кабул итте.** Визит барышында ул уку йортыбызның технологик үзәге, Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты, А.М.Бутлеров ис. Химия институты, Физика институты, Югары банк мәктәбе бар иде. Президент уку йорты җитәкчелеге, укытучылар, аспирант һәм студентлар белән очрашты.

**29 февраль көнне** «Татнефть Арена» боз сараенда «Универсиадага кадәр 500 көн» уңаеннан Волонтерларның «Без әзер!» дип аталган **I Бөтенроссия студентлар форумы узды**. Аның төп идеясе – Универсиаданы Россия яшьләренең милли проекты буларак кабул итү, «Казан – 2013» волонтерлык программасын популярлаштыру, вузара дуслыкны ныгыту.





## МАРТ

**Илшат Гафуров җитәкчелегендә Татарстанның Югары уку йортлары ректорлары киңәше булды.** Каралган мәсьәләләр арасында PayPass технологияләрен кертү, югары профессиональ уку йортларында Wi-Fiсистемасын булдыру, Универсиада-2013 әзерлек процесслары кебек мәсьәләләр бар иде.

**КФУның** Мәгълүмати технологияләр һәм системалар югары мәктәбе FlatSoft компаниясе белән берлектә **уртак лаборатория булдырды**.

**Март башларында** КФУ үсеш программасы кысаларында **Тел институтының ун доценты һәм укытучылары** CelTech (Германия) Электрон белем бирү технологияләре үзәгенең **«Бүгенге көндә электрон белем бирү: тенденция, технология һәм оештыру моментлары» дип исемләнгән тренинг семинарында катнашты**.

**XIX «Студентлар язы – 2012» фестиваленә старт бирелде.** «УНИКС» концертлар залында сайлап алу концертлары 10 көн буена сузылды.

**КФУда Һиндстан көннәре уңаеннан «Аңлашу турында»гы ике меморандумга кул куелды.** Беренчесе – Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты, Татарстан Республикасы һәм Һиндстанның Элемтәләрне үстерү мәдәни үзәге, икенчесе шул ук институт һәм Россия Федерациясендә Һиндстан илчелегенең Джавахарлала Неру исемендәге мәдәни үзәк арасында.

**КФУда мини-футбол буенча беренчелек башланды.** Чараның финал өлеше 14 мартта УНИКСның 1 залында узды. Беренче урынга Тарих институты лаек булды.

**Март урталарында КФУ делегациясе Сингапурга барды.** Анда Укытучылар Ассоциациясе белән хезмәттәшлек турындагы Меморандумга кул куелды.

**Журналистика һәм социология факультетында «Медиаполигон» проекты башланды.** Катнашучылар «Медиаполигон»да алган белем-күнекмәләрен «Шәһәр-24» проектында сынап карады.

**Яшьләр** сәясәте, иҗтимагый мәсьәләләр, физкультура һәм спорт тәр-

# тетының эшчәнлегенә еллык йомгак

биясе системасын үстерү департаменты Студентлар союзы һәм КФУ аспирантлары белән берлектә **«Точка зрения» V ачык халыкара фәнни-гамәли студентлар конференциясе уздырды**.

КФУда «Европа көннәре» **фестивале нигезендә күп төрле чаралар үткәрелде.** «Erasmus Mundus» программасы кысаларында академик мобильлек» мәгълүмати семинар һәм Россиядә Европа Союзы үзәге җитәкчеләре белән очрашу, «Европадагы кризис Россиягә яныймы?» исемле дебат булды, КФУның Евроклубына Европа Союзы Илчесе Фернандо Валенсуэло белән очрашу бәхете елмайды.

КФУ **студентлары һәм хезмәткәрләре** Бөтендөнья банкы директоры **Михаил Рутковский** (Польша) **белән очрашты**.

Танылган **галим, профессор Сергей Верёвкин КФУ студентлары өчен лекцияләр укыды.** «Матдәнең төзелеше һәм үзенчәлеге арасында









бәйләнеш. Бәя бирүнең универсаль методологиясе һәм чиста кушылмаларның термодинамик үзенчәлекләрен алдан күрү», «Яңа прогрессив материаллар. Ион сыеклыкларның табигатен аңлау: фактлар, кушымталар, проблемалар, экспериментлар» кебек ике өлештән торган лекция тәкъдим итте.

Кече **Филология һәм сәнгать институтын ачу тантанасы узды.** Алты структур юнәлештән торган Кече институтта 7-11 сыйныф укучыларына бушлай шөгыльләнү мөмкинлеге туды.

## АПРЕЛЬ

КФУда укучыларның Н.И.Лобачевский исемендәге **XIII Идел буе фәнни конференциясе узды.** Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган укучылар өчен 20 дән артык секция, укытучылар өчен «түгәрәк өстәл» эшләде.

Илшат Гафуров **җитәкчелегендәге КФУ делегациясе Калгаридагы Шлюмберже технология**



**үзәгенә барды.** Очрашуда бакалавриат, магистратура һәм аспирантура программалары буенча да мәсьәләләр каралды, аспирантлар әзерләү һәм студентлар алмашуга бәйле уртак программа кабул итү турында сөйләшү узды.

«Полиглот – 2013» **Бөтенроссия конкурсының финалы үтте.** Үзебезнең Казан федераль университетына 15 кешелек квота бирелде.

КФУның Тарих музеенда дөньяда беренче булып видеомагнитофон уйлап табучы һәм танылган «Ампекс» фирмасына нигез салучы **А.М.Понятовның тууына 120 ел булу уңаеннан чара үткәрелде**.

Илшат **Гафуров җитәкчелегендәге делегация** «Алабуга» үзенчәлекле икътисади зонасында кадрлар әзерләүгә багышланган **киңәшмәдә катнашты.** Ректор КФУда әзерләнә торган белгечләрнең бөтен дөньяга кирәк икәнлеген әйтте.

Макс Планкның йөрәк һәм үпкәләрне тикшерү институтыннан (Бад-Наухайм шәһәре, Германия) биология фәннәре докторы **Гельермо Баретто лекцияләр укыды.** Ул «ДНКга зыян килү һәм аны сәламәтләндерү», «Үпкәләрдәге яман шешнең эпигенетикасы» темасына лекцияләр укыды, ДНК метилациясен заманча өйрәнү ысулларына багышланган **семинар уздырды.**

Казан университетына РФдагы Индонезия республикасының Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле вәкиле **Джаухари Оратмангун килде.** Кунакны нигездә КФУ һәм Индонезия арасында физика, химия, лингвистика һәм икътисад юнәлешләре буенча хезмәттәшлек итү кызыксындырды.



Гёттинген университетының **славистика профессоры, Гёттинген Фәннәр академиясе вице-президенты Вернер Лефельдтка «Казан университетның мактаулы докторы» исеме бирелде**. Ул бу лаеклы исемгә Казан университеты историографиясен тикшергәне, бу өлкәдә эшчәнлек алып барганы өчен лаек.

Бөтенроссия экспериментать физика **фәнни-тикшеренү институтының Россия федераль үзәге җитәкчеләре** КФУга югары квалификацияле кадрлар әзерләгәне өчен **рәхмәт белдерде**.

КФУда хемо- һәм биоинформатикага **кагылышлы беренче семинар булды.** Чарада биология фәннәре докторы, профессор **Юрий Аульченко** (Роттердам, Голландия) кешенең статик геномикасы проблемаларына багышланган **чыгыш ясады**.

Юридик факультет **базасында** яшь юристлар өчен «Россия күләм Суд Дебатлары» дип аталган модельле **суд процессы оештырылды.** Чараның төп максаты студентларны чын суд эшләрендә катнашырга өйрәтү.

Быел **«Ягымлы яз»** татар студентларының ачык иҗат фестивале үзенең егерме яшьлек юбилеен билгеләп үтте. КФУдан да күп кенә студентлар чыгыш ясады һәм җиңүгә иреште.

Казан университетына Изге Климент Охридский исемендәге **София университетыннан делегация килде.** Очрашу вакытында традицион рәвештә хезмәттәшлек итү мәсьәләләре каралды.

КФУда **Саклык банкы корпоратив университетының төбәк мәйданчыгы ачылды.** Традицион белем бирүдән тыш, уңышлы юнәлешләр буенча дистанцион һәм проектлы укыту да булачак.

«УНИКС» концертлар залында **«Студентлар язы – 2012» фестиваленең Гала-концерты узды.** Җиңүче – Журналистика һәм социология факультеты.

Россия Фәннәр Академиясенең Казандагы региональ фәнни үзәгенең физика-техника институты директоры, КФУда химик физика кафедрасы җитәкчесе, **академик Кев Салихов Брукер премиясенә лаек дип табылды.** Бүгенге көндә Брукер премиясе Россиядән бары ике генә галимгә бирелгән

«XXI гасыр» **бию театры** (җитәкчесе И.Позняк) Мәскәүдә I Халыкара иҗади форум һәм «Иҗат планетасы» фестиваль-конкурсында **Гран-Прига лаек булды**.

## МАЙ

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 27 апрель көнне чыккан боерыгы нигезендә **Казан (Идел буе) федераль университетына Кама дәүләт инженерияикътисад академиясе кушылды.**

Казан **федераль университетында** химия өлкәсендә Нобель премиясе лауреаты, РИКЕН президенты (Япониянең Нагоя шәһәре физика-химия тикшеренү институты), **профессор Риоджи Нойори катнашында гыйльми советның тантаналы утырышы узды**. Япония галимнәренең чираттагы визиты барышында КФУ белән РИКЕН арасында фәнни хезмәттәшлек итү турындагы меморандумга кул куелды. Шулай ук Япониянең иң эре институты белән берлектә Физика институтында өч лаборатория ачылды.

КФУ **ректоры Илшат Гафуров РФ Президенты В.В.Путин инаугурациясендә катнашты**.

Ректор **җитәкчелегендәге КФУ делегациясе Кировка барды**. Биредә КФУ һәм Киров өлкәсе хакимияте арасында хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды.

КФУ Германиянең ике алдынгы югары уку йорты - Юстус–Либих исемендәге **Гиссен университеты** һәм М.Планк исемендәге **Йөрәк һәм үпкәләрне тикшерү институты белән килешү төзеде**.

КФУның татар филологиясе бүлеге тарафыннан **IV Бөтенроссия «Илһамлы каләм – 2012» әдәби әсәрләр конкурсы үткәрелде.** Россиянең төрле төбәкләреннән 332 кеше катнашты, Гран-Прига Актанышның 1 мәктәбеннән 11 сыйныф укучысы Гүзәл Фарсыева лаек булды.

Университетның **«Полит-сковородка» аталган студентларның сәяси дискуссион клубының ректор катнашында беренче утырышы узды**. Сәяси клуб утырышын ректор аычп җибәрде.

Казан федераль университеты **«Студентлар язы»** республика күләм ачык фестивалендә Гран-При яулады.



Россиянең элеккеге икътисад министры **Алексей Кудрин КФУда ачык лекция укыды.**

19 май көнне **КФУ ректоры Илшат Гафуров «Спортивное вещание» оешмасының генераль директоры Василий Кикнадзе белән очрашты.** Очрашуда яңалыкларны күзәтү өчен, журналистларны нәкъ менә безнең уку йорты студентлары арасыннан сайлау мәсьәләләре каралды.

Ректор **Илшат Гафуров җитәкчелегендәге Казан университеты делегациясе Япониягә барды.** И.Гафуров фундамендаль медицина һәм табигый фәннәр юнәлешендә хезмәттәшлек итүнең перспективалары хакында фикер алышуда катнашты.






## ИЮНЬ

КФУ **һәм Страсбург Университетында** «Хемоинформатика һәм молекуляр модельләштерү» белгечлеге буенча **бердәм магистратура ачу турында карар кылынды**.

Яр Чаллы шәһәрендәге **КФУ филиалы 15 еллык юбилеен билгеләп үтте.**

18 июнь көнне дөньяның алдынгы бизнес һәм хөкүмәт эшләрен алга җибәрү өлкәсендә эш-ләүче экспертларның берсе **доктор Ицхак Кальдерон Адизес Казан федераль университетында лекция укыды.** Университетыбыз кунагы хаталанудан курыкмаска, үзгәрешләргә һәрвакыт әзер булырга чакырды.



Лобачевский исемендәге фәнни китапханәдә **Samsung инновацияләре фестивале узды**. Очрашуда КФУ ректоры И. Гафуров һәм Samsung Electronics Rus Company генераль директоры Сул Ю үзара аңлашу турындагы меморандумга кул куйды.

Германиянең **Гиссен шәһәрендә** Россия-Германия мәгариф, фән һәм инновацияләр елы кысаларында **Россия атналыгы үткәрелде**, биредә КФУның 17 кешедән торган делегациясе катнашты.

Университетка Сингапурның Россиядәге илчеләре Лим Кхенг Хуа һәм Хенли Чен, Кореянең Пусан милли университеты профессоры Иль Ким һәм Чэнь Де Мин җитәкчелегендәге **Кытай делегациясе килде**.

Юридик факультетның өченче курсында белем алучы **Д.Хомяков авыр атлетика буенча дөнья беренчелегендә юниорлар арасында алтын медаль яулады.**

## ИЮЛЬ

Польшаның **Помор воеводалыгы губернаторы Мечислав Струк җитәкчелегендәге делегация КФУга килде.** КФУның Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе белән Польшаның политехника университеты арасында килешү төзү мөмкинлекләре турында сүз барды.

КФУның **ИТИС югары мәктәбендә Samsung Android Lab лабораториясе ачылды.** Лаборатория Android платформасы өчен кушымталар ясаучыларны әзерли. Ачылышта КФУ ректоры Илшат Гафуров, ТР Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдинов, Samsung компаниясе вәкиле Евгений Васильев, КФУның Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе директоры Айрат Хәсьянов катнашты.

## АВГУСТ

6 август көнне КФУның Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институтының 5 курс студенты **Юлия Зарипова Лондондагы Олимпия уеннарында каршылыклар аша 3000 метрга йөгереп алтын медаль яулады**. 12 август көнне шул ук институт чыгарылышы **Алексей Обмачаев Волейбол буенча Россия җыелма командасы составында Олимпия чемпионы булды.**

15-18 август **көннәрендә КФУның Алабуга институтында III Бөтенроссия мәктәп укытучылары фестиивале үткәрелде**. Чараны КФУ ректоры Илшат Гафуров ачып җибәрде. Фестивальдә Татарстан һәм Россия укытучылары һәм галимнәре генә түгел, чит илдән килгән белгечләр дә бар иде.

Дөньяның **төрле илләреннән барлыгы 360 тан артык галим 15 нче Халыкара аэрофизик метод белән эзләнүләр темасына багышланган конференциядә катнашты (ICMAR).**

КФУда **ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында «Университетның уку елына әзерлеге»дип исемләнгән киңәшмә булып үтте.** Президенттан тыш Казан мэры Илсур Метшин да килгән иде. Чара университетның ремонт барган биналарын караудан башланып китте. Шулай ук Президент КФУның дөньякүләм дәрәҗәгә җитү өчен мөмкинлекләре бик зур булуын искәртеп узды.

## СЕНТЯБРЬ

**1 сентябрь** көнне Казан федераль университеты базасында оешкан **IT-лицей сәләтле балалар өчен үзенең ишекләрен ачып җибәрде.**

**Универсиада** авылы янында студентлар өчен **яңа медицина үзәге барлыкка килде.** Шул рәвешле элеккеге студентлар поликлиникасы да медицина үзәгенә күченде.

**Быелгы Белем бәйрәмен КФУ студентлары Боз сараенда үткәрде.** Тантаналы бәйрәмдә ректор белән бергә Казан мэры И.Метшин, мәгариф һәм фән министры Э.Фәттахов, «Связьинвестнефтехим» ААҖ генераль директоры В.Сорокин да бар иде. Бәйрәм тамашасын Мәскәүдән килгән «Hi-Fi» төркеме дәвам итте. Студентлар өчен бәйрәм көне гадәттәгечә универсиада авылында дискотека белән тәмамланды.

**Казан** университетында эшләп танылган галим **Петр Францевич Лесгафтка 175 ел тулу уңаеннан чаралар үткәрелде.**

**Президент Рөстәм Миннеханов җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе составында КФУ ректоры Илшат Гафуров Карнеги Меллон университетында (Питтсбург, АКШ) рәсми очрашуга барды.** Очрашу нәтиҗәсендә ТР җитәкчелеге һәм Америка университеты арасында хезмәттәшлеккә кул куелды.

**КФУ үзенең эшчәнлеге нәтиҗәләрен «Нефть. Газ. Нефтехимия» XIX халыкара күргәзмәсендә тәкъдим итте.**



**Филология** һәм сәнгать институты студентлары Америка кинорежиссеры, «Оскар» премиясе лауреаты **Дэниел Лидси белән очрашты.**

**Австрия** фәннәр академиясенең квантлы физика институты директоры, Инсбрук университеты профессоры **Рудольф Гримм** КФУ укытучылары һәм студентлары өчен квантлы материя темасына мавыктыргыч **лекция укыды.**

**Казан федераль университетына Төркия Республикасы генераль консулы Сабри Тунч Ангылы килде.** Аның белән очрашуда Төркияне өйрәнү үзәге ачу, Юнус Эмре институты белән хезмәттәшлек итү мәсьәләләре каралды.

**КФУның** Физика институтында тантаналы рәвештә **җәмгать ашханәсе ачылды.** Хәзер студентларның туклану урыны кафедралардан бер дә ким түгел.

**Казан** федераль университетында хемоинформатика һәм биоинформатикага багышланган икенче **Франция-Россия семинары булып үтте.** Казан һәм Страсбург университетлары мондый семинарны ел саен оештыра.

**КФУның 300 вәкиле Бөтенроссия халыкара кроссында катнашты.**

**КФУның университет телевидениесе (*universmotri.ru*) онлайн режимда тәүлек буе эшли башлады.** Һәркем үзе теләгән вакытта кереп уку йортының тормышы белән таныша ала.

**КФУга ТР Президенты Рөстәм Миннеханов һәм Люксембург Премьер-министры Жан-Клод Юнкер җитәкчелегендәге делегация килде.** Алар уку йортында үткән бизнес-форумда катнашты.

**«Корстон» сәүдә һәм күңел ачу үзәгендә Россия фармокологлары съезды үтте.** Чараны оештыручыларның берсе – КФУ.





## ОКТЯБРЬ

**Идел буенда педагогик белем бирүгә 200 ел булу уңаеннан «КФУда өзлексез белем бирү концепциясе» исемле түгәрәк өстәл булды.** И.Гафуров педагогик юнәлештә белем бирә торган югары уку йортлары җитәкчеләре белән очрашты.

**Студентлар** хезмәт отрядының активистлары **«2013 агач» акциясендә катнашты.** Алар Калинино авылындагы урманга чыршы үсентеләрен утыртып, урманны саклауга үз өлешен керттеләр.

**Традицион рәвештә уздырыла торган «Беренче курслар көне» үтте.** Иҗади конкурсның гала-концертында кече группада беренче урынны Тарих институты, зур группада Филология һәм сәнгать институты яулады.



**КФУга** Кытай Халык Республикасы делегациясенең визиты кысаларында **ФСИ студентлары** кытай мәдәниятенең күренекле вәкиле **Ю.Вэйхун белән очраштылар.**

**Ректор Хуань педуниверситетының инновацион технологияләр буенча проректоры Куан Лэмань белән очрашты.** Ул «Россия һәм Кытай: тарихы һәм мәдәнияте» дип исемләнгән V халыкара фәнни-гамәли конференциядә катнашты.

**Университет** делегациясенең Польшага визиты кысасында **Вроцлав икътисади университет белән КФУ арасында хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды.**

**КФУның** Япониядә өйрәнү үзәгендә Японияднең Россиядәге мәдәният бүлеге хезмәткәре **С.Такэноучиның лекцияләре булды.**

**Ректор җитәкчелегендәге делегация** «Россия төбәкләрендә һәм шәһәрләрендә стратегик планлаштыру» дип исемләнгән **XI Бөтенроссия форумында катнашты.** Чараны әзерләү һәм үткәрүгә зур өлеш керткәне һәм катнашканы өчен И.Гафуров оргкомитетның рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

**КФУ студентлары Казан мэриясе булышлыгы белән «Балачак шатлыгы» хәйрия фонды оештырган мәрхәмәтлелек акциясендә катнашты.**

**КФУның** өлкән укытучысы **Лера Камалова «XI гасыр укытучысы» алтын медале** һәм милли белем бирү системасына зур өлеш керткәне өчен ЮНЕСКО бөтендөнья мәдәнияте институтының **«Европа-Азия» халык-ара гуманитар академиясенең дипломы белән бүләкләнде.**

**И.Гафуров Апас сайлау төбәге буенча РТ дәүләт советы депутатлары итеп сайланды.**

**Пекинда** узган халыкара мәгариф күргәзмәсендә **КФУ РФ Мәгариф һәм Фән Министрлыгының берләштерелгән экспозициясендә катнашты.**

**Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтында беренче тапкыр халыкара БМО көнен үткәрделәр.**

**Журналистика** һәм социология факультетының 50 яшьлек юбилее уңаеннан ректор катнашында **«Российская газета»ның баш мөхәррире В.Фронин белән очрашу булды.**

**15 тапкыр Завойский исемендәге яшьләр премиясенең тапшыру тантанасы узды.**

**«Ислам күп мәдәниятле дөньяда» II Халыкара форум узды.** Чарада Бельгия, Бөекбритания, Нидерланд, АКШ, Төркия, Япония, Украина, Азәрбайҗан, Польша, Әрмәнстан, Германия һәм Россиянең күп шәһәрләреннән ислам белгечләре катнашты.

## НОЯБРЬ

**Университетта** «Лобачевский укулары-2012» **XI Бөтенроссия яшьләр мәктәпконференциясе үтте.**

**Яр Чаллы шәһәрендәге ИНЭКА рәсми рәвештә КФУ филиалы составына керде.** Яңа структур бүлекнең директоры итеп **Мәхмүт Ганиев билгеләнде.**

**Лозанна Федераль политехник мәктәбе һәм КФУ арасында мәгариф һәм фән өлкәсе буенча хезмәттәшлек итү килешүенә кул куелды.**

**КФУ Идел буе Федераль округы ректорларын үзенә җыйды.**

**Теләче** районында ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы үткәргән җыелышта **КФУның абитуриентлар өчен эшли торган порталы тәкъдим ителде.**

**КФУга Вьетнам делегациясе килде. Очрашуның төп максаты – Вьетнам дәүләте белән хезмәттәшлек күпере салу.**

**Татарстан Республикасына визиты кысаларында университетка Корея Халык Демократик Республикасының Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле вәкиле Ким Дже килде.** КФУ Президенты Мәкъзүм Сәлахов белән очрашу барышында мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек итү турында фикер алыштылар.

**АКШтагы җиденче суд округының Федераль судлар администрациясе Т.Фицпатрик (Чикаго, АКШ) КФУга кунакка килде.** Аның Россиягә визиты «Ачык дөнья» закон чыгару тармагы өлкәсендә АКШ тәҗрибә алышу программасы белән бәйле.

**Уку йортыбызда тел белгечләре булмаган студентлар арасында Бөтенроссия «Полиглот» конкурсы узды.**

**Уку йортыбыз үзенең 208 еллык Туган көнен бәйрәм концерты белән билгеләп үтте.** Тантаналы Гыйльми Советта ректор Илшат Гафуров КФУның хәзерге торышы һәм киләчәккә планнары турында сөйләде.

**Физика институтына «Оптоэлектроника өчен гетероструктура.** Тарихы һәм хәзерге тенденцияләр» темасына лекция укыр өчен, Нобель бүләге лауреаты, РФ Дәүләт Думасы депутаты, галим Жорес Алферов килде.

**ТР мәгълүмати технологияләр өлкәсендә тикшеренүләр алып барыр өчен, КФУның Мәгълүмати технологияләр һәм югары системалар мәктәбенә махсус грант – бер миллион доллар бүлеп бирелде.**

**КФУ һәм РИКЕН уртак фәнни эшчәнлекне дәвам итү һәм үстерүгә юнәлтелгән икенче симпозиум җыйды.**

**Ректор И.Гафуров** һәм ТР фән һәм мәгариф министры **Э.Фәттахов катнашында педагогик белем бирү буенча Координацион советның беренче утырышы узды.**

**КФУ студентлары** «Вести в субботу» тапшыруының җитәкчесе һәм алып баручысы, «Россия» телеканалы директоры урынбасары **Сергей Брилев белән очрашты.**



**Россиянең алман теле буенча иң яхшы укытучы исеменә КФУдан Л.Закирова лаек дип табылды.**

**Рурс** университеты (Германия) профессоры **Клаус Вашик** укытуның креатив методлары: Рурс университеты тәҗрибәсе» исемле **лекцияләр укыды.**

**Казан һәм Көньяк федераль университетларының** студентлар җәмгыяте хезмәттәшлек турындагы **килешүгә кул куйды.**

**КФУның** гуманитар галимнәре РФның мәгариф өлкәсендә **Хөкүмәт премиясенә ия булдылар.**

## ДЕКАБРЬ

**Казан университетында Төркия Республикасының Казандагы Генераль Консулы Сабри Тунч Ангылы кунак булды.** Килүенең төп максаты – төрек уку йортлары һәм Казан университеты арасындагы хезмәттәшлекне ныгыту. Сабри Тунч Ангылы КФУ ректоры Илшат Гафуров белән шул өлкәгә кагылышлы мәсьәләләр буенча әңгәмә корды.

**5 декабрьдә Казан университетының Тарих музее янәдән талантлы студентларын җыйды.** Чарада «Казан федераль университеты һәм «Париж-3, Яңа Сорбонна» университетларының «филологик белем бирү» юнәлеше буенча уртак икеләтә дипломнар һәм рәсми рәвештә француз теле буенча Париж шәһәренең Сәүдә Сәнәгать Палатасы дипломнарын тапшыру булды.

**КФУда Н.И.Лобачевскийның 220 еллыгына багышланган чаралар үтте.** Шул хөрмәттән математика буенча Идел буе төбәге студентлары олимпиадасы, «Н.И.Лобачевский һәм Казан математика мәктәбе» студентлар конференциясе булды.

**Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты белән Япониянең Сайтам университетының гуманитар фәннәр факультеты арасында академик хезмәттәшлек турында килешү төзелде.**

**КФУга Франция вәкилләре: РФдагы Франция Вәкиллегенең хезмәттәшлек һәм мәдәният буенча киңәшчесе Уго де Шеваньяк һәм Академик хезмәттәшлек буенча атташесы Гийом Гаррет килде.**





Алар КФУ ректоры Илшат Гафуров белән хезмәттәшлек мәсьәләләрен хәл итте.

**Университетта Samsung классы ачылды.** Бу класс иң заманча технология буенча җиһазландырылган.

**Илшат Гафуров Мәскәүдә РФ Президенты Владимир Путин ышанычлылары белән очрашуда катнашты.**

**«КФУның ел студенты – 2012» бәйгесенең йомгаклау тантанасы булды.** Гран-Прига юридик факультетының бишенче курс студенты Роберт Зиннәтуллин лаек булды.

**КФУдагы Конфуций институтына биш ел тулды.** Шул уңайдан Кытайның Чанша шәһәрендә бәйрәм тантанасы үтте. Анда Тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов һәм КФУдагы Конфуций институты директоры Җәмил Зәйнуллин катнашты.

**КФУда Массакүләм коммуникация һәм социаль фәннәр институты барлыкка килде.** Аның директоры булып сәясәт фәннәре докторы, профессор Наил Мөхәррәмов билгеләнде.

**Казан** (Идел буе) федераль **университеты егетләре хоккей буенча Татарстан студентлар лигасында җиңү яулады.** Мондый ярыш Республикада беренче тапкыр үткәрелә.

**КФУ ректоры Илшат Гафуров Педагогика һәм психология институтында очрашу үткәрде.** Очрашуда уку-укыту мәсьәләсендә хезмәткәрләр белән фикер алыштылар.

**Татарстан** Мөселманнарының Диния нәзарәте, ТР Милли китапханәсе, Татарстан Язучылар берлеге һәм ТР Дәүләт Советының Мәдәният, Фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты оештырган **«Таян Аллага» конкурсында КФУ студенты Алмаз Мансуров Гран-Прига лаек булды.**

**Беренче** канал үткәргән **Бөтенроссия «Голос» тапшыруында КФУ студенты Динә Гарипова финалга чыкты.**

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Миннекаева, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева, Д.Р.Зиннәтова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева
А.Галимуллина, Д.Поварова, А.Фазлиахметов, Р.Гиниятов фотолары кулланылынды

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.